КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 22 декабрь г.Казань № 1265

«Воскресенский торак пунктына югары басымлы газүткәргеч» газ белән тәэмин итү системасының төбәк әһәмиятендәге линия объектын урнаштыру (реконструкциялəп, алга таба эксплуатацияләү) максатларында «Газстройпром» акционерлык җәмгыяте мәнфәгатьләрендә гавами сервитут билгеләү турында

Россия Федерациясе Җир кодексының $V^7$ бүлеге, «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль законның $3^6$ статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2000 елның 20 ноябрендәге 878 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасы нигезендә, «Воскресенский торак пунктына югары басымлы газүткәргеч» газ белән тәэмин итү системасының төбәк әһәмиятендәге линия объектын урнаштыру (реконструкциялəп, алга таба эксплуатацияләү) максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Воскресенский торак пунктына югары басымлы газүткәргеч» газ белән тәэмин итү системасының төбәк әһәмиятендәге линия объектын урнаштыру (реконструкциялəп, алга таба эксплуатацияләү) максатларында «Газстройпром» акционерлык җәмгыяте мәнфәгатьләрендә кушымтада күрсәтелгән җир кишәрлекләренә (алга таба – җир кишәрлекләре) карата 10 елга гавами сервитут (алга таба – гавами сервитут) (ИНН 7842155505, ОГРН 1187847178705) билгеләргә.

2. Бу карарга теркәлгән «Воскресенский торак пунктына югары басымлы газүткәргеч» газ белән тәэмин итү системасының төбәк әһәмиятендәге линия

объектын урнаштыру (реконструкциялəп, алга таба эксплуатациялəү) максатларында гавами сервитут чиклəре урнашу урынының график тасвирламасын расларга.

3. Түбəндəгелəрне билгелəргə:

гавами сервитут өчен түлəүне исəплəү һəм кертү тəртибе Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{46}$ статьясы нигезендə гамəлгə ашырыла;

җир кишəрлеклəреннəн рөхсəт ителгəн файдалану нигезендə алардан файдалану мөмкин булмаячак яки шактый авыр булачак срогы гавами сервитут срогына туры килə.

4. Татарстан Республикасы Җир һəм мөлкəт мөнəсəбəтлəре министрлыгына бу карар кабул ителгəн көннəн биш эш көне эчендə законнар белəн билгелəнгəн тəртиптə түбəндəгелəрне тəэмин итəргə:

бу карарны Татарстан Республикасы Җир һəм мөлкəт мөнəсəбəтлəре министрлыгының «Интернет» мəгълүмат-телекоммуникация челтəрендəге рəсми сайтында урнаштыруны;

бу карарны муниципаль хокукый актларны рəсми бастырып чыгару өчен билгелəнгəн тəртиптə рəсми бастырып чыгару өчен Татарстан Республикасының Кайбыч муниципаль районына җибəрүне;

бу карарның күчермəлəрен «Газстройпром» акционерлык җəмгыятенə, «Дəүлəт теркəве, кадастр һəм картография федераль хезмəтенең Федераль кадастр палатасы» федераль дəүлəт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалына, җир кишəрлеклəренең хокук иялəренə җибəрүне.

5. «Газстройпром» акционерлык җəмгыятенə түбəндəгелəрне тəкъдим итəргə:

җир кишəрлеклəренең хокук иялəре белəн гавами сервитутны гамəлгə ашыру турында килешүлəр төзүне;

Россия Федерациясе Хөкүмəтенең «Газ бүлү челтəрлəрен саклау кагыйдəлəрен раслау турында» 2000 елның 20 ноябрендəге 878 номерлы карары нигезендə газ бүлү челтəрлəренең саклау зонасы чиклəрен һəм газ бүлү челтəрлəренең саклау зонасы чиклəре турындагы мəгълүматларны раслау хакындагы гариза белəн Татарстан Республикасы Җир һəм мөлкəт мөнəсəбəтлəре министрлыгына мөрəҗəгать итүне;

бу карарның 1 пунктында күрсəтелгəн газ белəн тəэмин итү объектына техник хезмəт күрсəтү буенча тəэмин ителеше өчен гавами сервитут билгелəнгəн план (регламент) эшлəрен елга бер тапкыр гамəлгə ашыруны;

җир кишəрлеклəрен аларның рөхсəт ителгəн файдалану төре нигезендə файдалану өчен яраклы хəлгə китерүне;

гавами сервитут нигезендə урнаштырылган инженерлык корылмасын, тəэмин ителеше өчен гавами сервитут билгелəнгəн эшчəнлек тəмамланганнан соң, Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{50}$ статьясында билгелəнгəн срокларда сүтүне.

6. Бу карарның үтəлешен тикшерүдə тотуны Татарстан Республикасы Җир һəм мөлкəт мөнəсəбəтлəре министрлыгына йөклəргə.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 21 декабрь, 1265 нче
карарына кушымта

«Воскресенский торак пунктына югары басымлы газүткәргеч» газ белән тәэмин итү системасының
төбәк әһәмиятендәге линия объектын урнаштыру (реконструкцияләп, алга таба эксплуатацияләү) максатларында
гавами сервитут билгеләнә торган
җир кишәрлекләре исемлеге

| Т/с | Җир кишәрлегенең кадастр номеры | Бердәм җирдән файдалануның кадастр номеры | Җир кишәрлегенең хокук иясе | Хокук төре | Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар нигезендә җир кишәрлегенең урнашу урыны | Гавами сервитут урнаштырыла торган мәйдан, кв.метр |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | 16:21:040604:6<br>16:21:040604:13<br>16:21:040604:11 | 16:21:000000:7 | «Ярдәм» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | Милек | Татарстан Республикасы, Кайбыч муниципаль районы | 10 717 |
| Барлыгы | | | | | | 10 717 |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 21 декабрь, 1265 нче
карарына кушымта

«Воскресенский торак пунктына югары басымлы газүткәргеч»
газ белән тәэмин итү системасының төбәк әһәмиятендәге линия объектын урнаштыру (реконструкцияләп, алга таба эксплуатацияләү) максатларында гавами сервитут чикләре урнашу урынының
график тасвирламасы

1 бүлек

| Объект турында мәгълүматлар | | |
|---|---|---|
| Т/с | Объектның тасвирнамәләре | Тасвирнамәләрнең тасвирламасы |
| 1 | Объектның урнашу урыны | Татарстан Республикасы, Кайбыч муниципаль районы, Ульянково авыл җирлеге |
| 2 | Объектның мәйданы +/- мәйданны билгеләү төгәлсезлеге зурлыгы (Р +/- Дельта Р) | 10 717 кв.м +/- 36 кв.м |
| 3 | Объектның башка тасвирнамә-ләре | Гавами сервитут билгеләнә торган җир кишәрлекләренең кадастр номерлары:<br>16:21:040604:6 (16:21:000000:7),<br>16:21:040604:13 (16:21:000000:7),<br>16:21:040604:11 (16:21:000000:7) |

2 бүлек

| Объект чикләренең урнашу урыны турында мәгълүматлар | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. Координатлар системасы: Халыкара координатлар системасы – 16 | | | | | |
| 2. Объект чикләренең характерлы нокталары турында мәгълүматлар | | | | | |
| Чикләрнең характерлы нокталары билгесе | Координатлар, м | | Характерлы ноктаның координатларын билгеләү ысулы | Характерлы нокта урынының уртача квадрат төгәлсезлеге (Mt), м | Җирлектә нокта билге-сенең тасвир-ламасы (булган-да) |
| | X | Y | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| - | - | - | - | - | - |
| 3. Объект чиге өлешенең (өлешләренең) характерлы нокталары турында мәгълүматлар | | | | | |
| Чик өлешенең характерлы нокталары билгесе | Координатлар, м | | Характерлы ноктаның координатларын билгеләү ысулы | Характерлы нокта урынының уртача квадрат төгәлсезлеге (Mt), м | Җирлектә нокта билге-сенең тасвир-ламасы (бул-ганда) |
| | X | Y | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1 өлеш | | | | | |
| 1 | 431511.49 | 1234472.78 | Аналитик ысул | 0.1 | - |
| 2 | 431521.18 | 1234484.23 | Аналитик ысул | 0.1 | - |
| 3 | 431486.30 | 1234513.77 | Аналитик ысул | 0.1 | - |
| 4 | 431479.16 | 1234519.84 | Аналитик ысул | 0.1 | - |
| 5 | 431509.10 | 1234631.27 | Аналитик ысул | 0.1 | - |
| 6 | 431543.87 | 1234760.70 | Аналитик ысул | 0.1 | - |
| 7 | 431537.92 | 1234777.04 | Аналитик ысул | 0.1 | - |
| 8 | 431498.53 | 1234630.46 | Аналитик ысул | 0.1 | - |
| 9 | 431486.19 | 1234584.53 | Аналитик ысул | 0.1 | - |
| 10 | 431437.88 | 1234597.44 | Аналитик ысул | 0.1 | - |
| 11 | 431428.60 | 1234562.73 | Аналитик ысул | 0.1 | - |
| 12 | 431421.84 | 1234568.43 | Аналитик ысул | 0.1 | - |
| 13 | 431400.70 | 1234586.25 | Аналитик ысул | 0.1 | - |
| 14 | 431391.00 | 1234574.79 | Аналитик ысул | 0.1 | - |
| 15 | 431402.36 | 1234565.18 | Аналитик ысул | 0.1 | - |
| 16 | 431388.40 | 1234514.88 | Аналитик ысул | 0.1 | - |
| 17 | 431405.35 | 1234510.18 | Аналитик ысул | 0.1 | - |
| 18 | 431479.34 | 1234489.63 | Аналитик ысул | 0.1 | - |
| 19 | 431497.56 | 1234484.57 | Аналитик ысул | 0.1 | - |
| 1 | 431511.49 | 1234472.78 | Аналитик ысул | 0.1 | - |
| 2 өлеш | | | | | |
| 20 | 431547.68 | 1234768.28 | Аналитик ысул | 0.1 | - |
| 21 | 431558.95 | 1234785.19 | Аналитик ысул | 0.1 | - |
| 22 | 431543.80 | 1234824.82 | Аналитик ысул | 0.1 | - |
| 23 | 431544.72 | 1234802.36 | Аналитик ысул | 0.1 | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| 24 | 431540.71 | 1234787.43 | Аналитик ысул | 0.1 | - |
| 20 | 431547.68 | 1234768.28 | Аналитик ысул | 0.1 | - |


3 бүлек

| Объектның үзгәртелгән (тәгаенләнгән) чикләренең урнашу урыны турында мәгълүматлар | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. Координатлар системасы: Халыкара координатлар системасы – 16 | | | | | | | |
| 2. Объект чикләренең характерлы нокталары турында мәгълүматлар | | | | | | | |
| Чикләрнең характерлы нокталары билгесе | Гамәлдәге координатлар, м | | Үзгәртелгән (тәгаенләнгән) координатлар, м | | Характерлы ноктаның координатларын билгеләү ысулы | Характерлы нокта урыныың уртача квадрат төгәлсезлеге (Mt), м | Җирлектә нокта билгесенең тасвирламасы (булганда) |
| | X | Y | X | Y | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| - | - | - | - | - | - | - | - |
| 3. Объект чиге өлешенең (өлешләренең) характерлы нокталары турында мәгълүматлар | | | | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| - | - | - | - | - | - | - | - |

4 бүлек

«Воскресенский торак пунктына югары басымлы газүткәргеч» инженерлык корылмасын реконструкцияләү максатларында гавами сервитут чикләре урнашу схемасы

Объект чикләренең күзәтү схемасы




Масштабы 1: 25 000

Файдаланыла торган шартлы билгеләр һәм тамгалар


– объект чиге

– авыл җирлеге чиге.

4 бүлек

**«Воскресенский торак пунктына югары басымлы газүткәргеч» газ белән тәэмин итү системасының төбәк әһәмиятендәге линия объектын урнаштыру (реконструкцияләп, алга таба эксплуатацияләү) максатларында гавами сервитут чикләре урнашу урыны схемасы**

1 нче бит




Масштабы 1: 2 000

Файдаланыла торган шартлы билгеләр һәм тамгалар

• **1** – объект чикләренең характерлы ноктасы билгесе

– объект чиге

– инженерлык корылмасының проектта урнашу урыны (газүткәргеч күчәре)

– демонтажлана торган корылманың урнашу урыны (демонтажлана торган газүткәргеч күчәре)

– кадастр кварталы чиге

– Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестры мәгълүматлары буенча җир кишәрлекләре чиге

16:21:040604 – кадастр кварталы номеры

16:21:040604:13 – җир кишәрлегенең кадастр номеры.